СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 24 » март 2020 ел №6

**2020 елда Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендә
салым чыгымнары исемлеген формалаштыру
һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^3$ статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 сентябрьгә кадәр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенә хисап елы, хисап елына кадәрге ел өчен түбәндәге мәгълүматлар җибәрергә:

ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең һәр салым кереме буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге бюджетына керми калган керемнәр суммалары турында.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Наласа авыл
җирлеге башлыгы: Шакирова И.Р

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегенең
“24”03. 2020 ел, №6
карары белән расланган

2020 елда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү кагыйдәләрен билгели (алга таба-тәртип, муниципаль берәмлек).

2. Әлеге тәртиптә «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр буенча (алга таба-Гомуми таләпләр) билгеләнгән терминнар һәм төшенчәләр кулланыла.

3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар, муниципаль программаларның структур элементлары һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында, муниципаль берәмлек башкарма комитеты:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзи;

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен анализлауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра.

## II. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары Исемлеге муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан төзелә һәм агымдагы елның 1 июненә кадәр раслана.

6. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының расланган Исемлеге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

7. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе муниципаль берәмлек башкарма комитетына хисап финанс елы өчен һәм хисап чорына кадәрге ел өчен муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының фискаль характеристикалары турында мәгълүмат бирә.

8. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру максатларында, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты ел саен 1 августка кадәр Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә муниципаль берәмлекнең тиешле салым чыгымнарын, шул исәптән хисап елында һәм алдагы хисап елында гамәлдә булган норматив хокукый актларын һәм әлеге Тәртипкә кушымтада каралган башка мәгълүматны күрсәтеп, түләүчеләр категорияләре турында белешмәләр җибәрә.

9. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә кертелгән мәгълүматны үзгәртүне күздә тоткан норматив хокукый актлар кабул ителгән очракта, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тиешле норматив хокукый акт үз көченә кергән көннән соң 10 эш көне эчендә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары Исемлегенә тиешле үзгәрешләр кертә.

**III. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү тәртибе.**

10. Салым чыгымнарын бәяләү муниципаль берәмлек башкарма комитеты тарафыннан башкарыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары күләмнәрен бәяләү;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү.

11. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчанлыгын бәяләү;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү.

12. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчанлыгы критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарының муниципаль программа максатларына, муниципаль программаларның структур элементларына һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

ташламалардан файдаланучы салым түләүчеләрнең саны һәм бишьеллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны белән чагыштыруы белән характерлана торган салым ташламаларына ихтыяҗ булу.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә булса да туры килмәсә, муниципаль берәмлек башкарма комитетына түләүчеләр өчен ташламаларны саклау (аныклау, юкка чыгару) турында тәкъдимнәр әзерләргә кирәк.

13. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының нәтиҗәлелек критерие буларак муниципаль программа максатларына яисә муниципаль программаларга керми торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең ким дигәндә бер күрсәткече (индикаторы) яисә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары йогынты ясый торган башка күрсәткеч (индикатор) буларак билгеләнә. Әлеге күрсәткеч (күрсәткечләр) агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына, хисап елына, аннан алдагы елга һәм план чорына билгеләнә.

Түләүчеләр өчен каралган ташламалар муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль программаларга кермәгән муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткече (индикаторы) дәрәҗәсен үзгәртүгә кертелгән ташламаларны исәпкә алмыйча һәм исәпкә алып, күрсәтелгән күрсәткечнең (индикаторның) әһәмияте арасындагы аерма буларак исәпләнә.

14. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә ала.

15. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына кермәгән социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелегенә һәм ташламалар бирү нәтиҗәлелегенә чагыштырмача анализ ясала.

16. Чагыштырма анализ муниципаль берәмлекнең муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану очрагында муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары күләмнәрен һәм бирелгән ташламалар күләме артуын һәм муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына керми торган муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының 1 сумына һәм шул ук

күрсәткечкә (индикатор) ирешү өчен муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының 1 сумына чагыштыруны үз эченә ала.

Муниципаль берәмлекнең муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнары сыйфатында түбәндәге муниципаль берәмлек исәпкә алынырга мөмкин:

а) муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән ташламалар алу хокукына ия түләүчеләргә турыдан-туры финанс ярдәменең субсидияләре яисә башка формалары;

б) ташламаларга хокукы булган түләүчеләрнең йөкләмәләре буенча муниципаль гарантияләр бирү;

в) ташламаларга хокукы булган түләүчеләр эшчәнлеге өлкәсендә норматив җайга салуны һәм (яки) контроль-күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыру тәртибен камилләштерү.

17. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү 1 октябрьгә кадәр башкарыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- салым чыгымнарын бәяләү күрсәткечләре Исемлеге буенча мәгълүмат;

- салым чыгымнарының максатчан характеристикаларына ирешү (ирешмәү), муниципаль программа максатларына һәм (яки) социаль-икътисадый сәясәт юнәлешләренә (максатларына) ирешүгә салым чыгымының кертеме турында нәтиҗәләр тупланган язмача аңлатма;

- аларга ирешү өчен нәтиҗәлерәк альтернатив механизмнар булу (булмау) турында тәкъдимнәр;

- салым чыгымнарын саклау, аныклау (юк итү), яңа салым чыгымнарын билгеләү буенча тәкъдимнәр.

18. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләре муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендә
салым чыгымнары исемлеген формалаштыру
һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибенә
кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлегендә
салым чыгымнарына бәяләү үткәрү күрсәткечләре исемлеге

| Күрсәткеч атамасы | | Мәгълүматлар чыганагы |
|---|---|---|
| I. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының норматив һәм максатчан характеристикалары | | |
| 1. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламалары, салымнан азат итү һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 2. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, салымнан азат итү һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 3. | Салым ташламалары, салымнан азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 4. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, салымнан азат итү һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 5. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, салымнан азат итүгә һәм салымнар буенча бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлдә булу датасы | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 6. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, салымнан азат итүләренең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 7. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларының, салымнан азат итүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булуын туктату датасы | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 8. | Салым ташламаларының, салымнан азат итүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең исеме | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Салым чыгымнарының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташлама) | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 10. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым түләүчеләр өчен салым ташламалары, салымнан азат итү һәм башка преференцияләр бирү максатлары | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 11. | Салым ташламалары, салымнан азат итү һәм муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән башка преференцияләр каралган салым исемнәре | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 12. | Түләүчеләрнең аерым категорияләренә бирелгән салым ташламаларының, салымнан азат итүләренең һәм башка преференцияләрнең башка түләүчеләр белән чагыштырганда өстенлекләре үзенчәлекләрен билгели торган төре | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 13. | Салым ташламалары, салымнан азат итү һәм салымнар буенча башка преференцияләр бирелә торган салым ставкасы күләме | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 14. | Салым ташламалары, салымнан азат итүләр һәм салымнар буенча башка преференцияләр бирү белән бәйле рәвештә муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына һәм (яисә) муниципаль программа максатларына ирешү күрсәткече (индикаторы) | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| II. Салым чыгымнарының фискаль характеристикасы | | |
| 15. | Хисап елы өчен һәм хисап елына кадәр булган ел өчен муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары нигезендә салым ташламалары, салымнан азат итүләр һәм башка преференцияләр күләме (мең сум) | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| 16. | Агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, салымнан азат итүләр һәм башка преференцияләр күләмен бәяләү (мең сум) | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
| 17. | Салым ташламасыннан, азат итүдән һәм муниципаль берәмлекнең хокукый актларында билгеләнгән башка преференциядән файдаланган салым түләүчеләр саны | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| 18. | Салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре | Муниципаль берәмлек башкарма комитеты |